| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Красноборского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Красный Бор авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

02.07.2018 Красный Бор авылы № 36-1

Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Советы карары 16.06.2014 №35-1 белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Красный Бор авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Положениега үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль закон 2 март 2007 ел № 25-ФЗ, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы 25 июнь 2013 ел №50-ЗРТ, “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” гы Закон 22 март 2018 ел № 15-ЗРТ, 23 декабрь 2017 №98-ЗРТ, “Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләреертү турында” 14 декабрь 2017 ел № 90-ЗРТ, “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 19 июль 2017 ел № 55- ЗРТ, “Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләр кертү турында”гы Законнар 29 сентябрь 2016 ел № 72-ЗРТ нигезендә Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Положениега Красный Бор авыл җирлеге Советы раслаган карар 16.06.2014 №35-1 белән 1 кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына куярга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтына agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталына pravo.tatarstan.ru урнаштырырга .
3. Әлеге карарны тормышка ашыруга контрольне үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе А.Н. Лазарев

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлеге Советы карарына 1 нче кушымта 02.07.2018 №36-1 белән расланган

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Красный Бор авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә “Муниципаль хезмәт турында”гы Положениега кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр

**1. 5 маддәнең 5.6. өлешендәге “Муниципаль хезмәт вазифалары”:**

“Югары группа хезмәтләрнең белеме” бүлегенә өстәргә:

“2020 елның 1 октябренә кадәр муниципаль хокукый карарлар белән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретарь) вазифасын алыштыру өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә квалификацион таләпләр урта һөнәри белем һәм муниципаль хезмәт стажында яки белгечлек буенча эшләү стажында кимендә ике ел яки кимендә өч ел булырга мөмкин”.

**2. 10 маддәнең 10 пункт 10.1 өлеше “Муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр” түбәндәге редакциядә язарга:**

“Россия Федерациясе субъектындагы чакыру комиссиясенә заключениене инкаръ итү өчен билгеләнгән вакыт узганнан соң 10 ел дәвамында законлы нигезе булмыйча хәрби хезмәт узмавын танырга (контракт буенча хәрби хезмәт узган гражданнардан кала). Әгәр чакыру комиссиясе заключениесе яки карары гражданин гаризасы буенча әлеге заключение судка бирелгән булса, – чакыру комиссиясе заключениесе яки карарын чыгарганда гражданинның хокуклары бозылмаган булуын раслаган суд карары законлы көченә кергән көннән башлап 10 ел дәвамында.

**11 маддәнең 3 пунктын яңа редакциядә язарга:**

“16) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерция оешмасы яки коммерция оешмасы булмаган оешма белән идарә итәргә (сәяси партия белән итүдә катнашудан тыш); торак-төзелеш, гараж кооперативы, күчемсез милек ширкәтләре, бакчачылык, дача кооперативлары съездларында (конференцияләр) катнашу; Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән оешма белән идарә итүдән тыш, әлеге коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә башкарма орган сыйфатында катнашу яки билгеләнгән муниципаль хокукый акт тәртибендә эш бирүченең рөхсәте белән аларның коллегиаль орган составына керү”.

**3. 15 маддә 15.1.1 бүлек**

“15.1.1. Муниципаль хезмәт вазифасын алыштыруга конкурс үткәрү тәртибе Иске Эсләк авыл җирлеге Советы кабул иткән муниципаль хокукый акт белән билгеләнә. Конкурс үткәрү тәртибе конкурс үткәргәнгә кадәр 20 көн алдан аның шартларын, көнен, вакытын, үткәрү урынын, хезмәт килешүе проектын бастыруны

исәпкә алырга тиеш. Муниципаль берәмлектә конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны һәм аны формалаштыру тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә. Җирле хакимиятнең территориаль органы җитәкчесе вазифасын алыштыруга конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясен формалаштыру өчен аның составына авыл торак пунктларының һәрберсендә үткәрелгән гражданнар җыеннарында күрсәтелгән кандидатларны кертүне искә алырга”.

**4. 20 маддә “Муниципаль хезмәткәрнең керемнәре, чыгымнары, милке, милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр” яңа редакциядә язарга:**

“20.1.1. Муниципаль хезмәт вазифасын алыштыруга дәгъвачы гражданнар, әлеге вазифаны алыштыручы муниципаль хезмәткәрләр эш бирүчегә үзенең һәм җәмәгатенең, балигъ булмаган балаларының кереме, милке, милек характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш. Әлеге белешмәләр билгеләнгән тәртиптә, срокта һәм формада тапшырыла.

20.1.2. Муниципаль хезмәт вазифасын алыштыручы муниципаль хезмәткәр үзенең, җәмәгатенең һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә һәм формада тапшырырга тиеш.

20.1.3. Муниципаль хезмәткәрнең, җәмәгатенең, балигъ булмаган балаларының керемнәре белән чыгымнары тәңгәл килүенә контроль “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль закон, “Дәүләт вазифаларын алыштыручы затның керемнәре белән чыгымнары тәңгәллегенә контроль турында” Федераль закон 3 декабрь 2012 № 230-ФЗ, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары, Кодекс, Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә башкарыла.

20.1.4. Әлеге маддә нигезендә муниципаль хезмәткәр бирә торган керемнәр, чыгымнар, милек турындагы белешмәләр, әгәр алар дәүләт һәм башка саклана торган сер белешмәренә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып санала.

20.1.5. Муниципаль хезмәткәрнең, җәмәгатенең һәм балигъ булмаган балаларының керемнәр, чыгымнар милке турындагы белешмәләрне түләү сәләтен билгеләү, дини, башка иҗтимагый оешмаларга взнослар, акчалата ярдәм күрсәтүдә файдалану тыела.

20.1.6. Муниципаль хезмәткәрнең керемнәре, чыгымнары, милке турындагы белешмәләрне читкә тараткан яки аларны башка максатларда файдаланган гаепле зат закон нигезендә җаваплылыкка тартыла.

20.1.7. Әгәр мондый белешмәләр бирү мәҗбүри икән, муниципаль хезмәткәр, аның җәмәгате һәм балигъ булмаган балалары керем, чыгым, милек турындагы белешмәләрне тапшырмаса, яки ялган, дөрес булмаган белешмәләр тапшырса, муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәттән чыгарыла.

20.1.8. Муниципаль хезмәт вазифасын алыштыруга дәгъвачы гражданнарның керемнәр, чыгымнар, милек турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары һәм милке турындагы белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылылыгы, муниципаль хезмәткәрнең чикләүләрне һәм тыюларны, вазифаларын башкаруны тикшерү Татарстан

Республикасы Президентының норматив хокукый актлары билгеләгән тәртиптә башкарыла.

20.1.9. Банк, салым һәм закон нигезендә сер булып саклана торган белешмәләр, муниципаль хезмәт вазифасын алыштырырга дәгъвачыга, муниципаль хезмәткәрләргә, аларның җәмәгатьләренә, балигъ булмаган балаларына карата оператив- тентү чаралары үткәрү турында хокук саклау органнарына белешмәләр соратып алу Россия Федерациясе норматив хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан җибәрелә.

20.1.10. Коррупция һәм башка хокук бозуларны кисәтү, муниципаль хезмәтне алыштыручының, аның җәмәгатенең һәм балигъ булмаган балаларының керемнәренә контроль итүче җаваплы зат Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

20.1.11. Контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазифасын алыштыручыга дәгъва кылучы һәм әлеге вазифаны алыштыручы, аның җәмәгате, балигъ булмаган балалары керемнәре, чыгымнары, милке турынд белешмәне Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына тапшырыла.

20.1.12. Контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазифасын алыштыручы зат тапшырган керемнәр, чыгымнар, милек турындагы белешмәләр муниципаль хоукый актлар билгеләгән тәртиптә Интернетта җирле үзидарә органынын рәсми сайтына куела һәм(яки) массакүләм мәгълүмат чараларында басу өчен тапшырыла.

20.1.13. Керемнәр, чыгымнар, милек турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты карары белән үткәрелә.

20.1.14. Тикшерү нәтиҗәләре буенча контракт нигезендә җирле үзидарә башлыгын алыштыручы затның үз вазифаларын, чикләүләрне, тыюларны үтәмәве ачыкланган очракта Татарстан Республикасы Президенты аның вазифаларын вакытыннан алда туктату яки аңа карата башка дисциплинар чара күрү турында җирле үзидарә органына яки судка гариза белән мөрәҗәгать итә.

20.2. Белешмәләрне ”Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тапшыру

20.2.1. Муниципаль хезмәт вазифасына дәгъва кылучы, муниципаль хезмәткәр Интернеттагы сайт адреслары һәм (яки) сайт битләре турында белешмәне, мәгълүматны эш бирүче вәкиленә тапшыра:

1) муниципаль хезмәт вазифасына дәгъва кылучы гражданин муниципаль хезмәткә керешкәнче эшләгән өч ел;

2) муниципаль хезмәткәр – һәр елны календарь ел өчен.

20.2.2. Муниципаль хезмәткә дәгъва кылучы бу вазифага керешкәндә, муниципаль хезмәткәр белешмәләрне 1 апрельгә кадәр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән форма буенча тапшыра.

20.2.3. Эш бирүче вәкиле карары белән билгеләнгән муниципаль хезмәткәр вәкилләре муниципаль хезмәткә дәгъва кылучының интернетка куйган мәгълүматларын эшкәртә, аларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерә.

**5. “Муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы” 23 маддәсен яңа редакциядә язарга:**

“23. Муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы. Чикләүләрне, тыюларны, коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җәза.

23.1. Муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы.

23.1.1. Муниципаль хезмәткәр гаебе белән аңа йөкләнгән вазифаларны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен эш бирүче түбәндәге җәзаларны кулланырга хокуклы:

1) шелтә;

2) кисәтү;

3) муниципаль хезмәттән эштән  чыгару.

23.1.2. Дисциплинар эш кылган муниципаль хезмәткәр вакытлыча ( бер айдан артмаска тиеш), дисциплинар җаваплылык турында мәсьәлә хәл ителгәнче, хезмәт хакын саклап, вазифаларын башкарудан азат ителергә мөмкин. Муниципаль хезмәткәрне вазифаларыннан читләштерү муниципаль хокук акты белән башкарыла.

23.1.3. Дисциплинар җәза бирү һәм аны кире алу тәртибен куллану хезмәт законнары белән билгеләнелә.

23.2. Чикләүләр һәм тыюларны үтәмәгән, коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән йөкләмәләрне, низагларны булдырмау һәм аларны көйләү таләпләрен үтәмәгән өчен җәза.

23.2.1. Муниципаль хезмәткәр ”Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”, “Коррупциягә каршы көрәш турында” федераль законнар нигезендә билгеләнгән чикләүләр, тыюларны, конфликтларны булдырмау һәм көйләү таләпләрен үтәмәгән өчен әлеге Положениенең 23маддәсе 23.1 пунктында каралган җәза бирелә.

23.2.2. Муниципаль хезмәткәр әлеге Положениенең 12, 20 маддәләрендә каралган хокук бозуларны кылса, ышанычны югалту сәбәпле, муниципаль хезмәттән эштән чыгарыла.

23.2.3. Эш бирүче әлеге Положениенең 12, 20 маддәләре, 23 маддәнең 23.1 пунктында каралган җәзаларны  түбәндәге нигезләрдә куллана:

1) тикшерү нәтиҗәләре турындагы доклад;

2) әгәр тикшерү нәтиҗәләре  муниципаль хезмәткәрнең хезмәт таләпләрен саклау буенча комиссиягә җибәрелгән очракта әлеге комиссиянең рекомендациясе;

3) муниципальхезмәткәрнең аңлатмасы;

4) башка материаллар.

23.2.4. Тикшерү үткәрү өчен түбәндәге органнардан язма рәвештә бирелгән мәгълүмат санала:

1) хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның җаваплы затлары;

2) сәяси партияләрнең региональ яки җирле бүлекчәләре,сәяси партия булмаган региональ иҗтимагый берләшмәләр;

3) муниципаль берәмлектәге иҗтимагый совет;

4) массакүләммәгълүмат чаралары.

23.2.5. аноним хәбәр тикшерү өчен нигез була алмый.

23.2.6. Тикшерү үткәрү өчен муниципаль хезмәткәрдән язма аңлатма таләп итәргә кирәк. Әгәр ике эш көненнән соң әлеге аңлатма бирелмәсә, акт төзелә. Муниципаль хезмәткәрнең әлеге аңлатманы бирмәве тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора алмый.

23.2.7. Әгәр муниципаль хезмәткәр Положениенең 12 маддәсе 12.5 яки 12.7 пунктларында каралган хокук бозуларны кылса, тикшерү нәтиҗәләре буенча доклад, муниципаль хезмәткәрнең язмача аңлатмасы муниципаль хезмәткәрнең хезмәт таләпләрен саклау комиссиясенә тапшырыла. Комиссия эш бирүчегә муниципаль хезмәткәргә карата дисциплинар җәза куллану турында рекомендацияләр әзерли.

23.2.8. Положениенең 12, 20 маддәләр, 23 маддәнең 23.1 пунктында каралган җәза бирүне кулланганда муниципаль хезмәткәр кылган коррупцион хокук бозуларның характеры, авырлыгы, аны кылгандагы шартлар, башка чикләүләрне, тыюларны үтәве, вазифаи бурычларын элек үтәве нәтиҗәләре исәпкә алына.

23.2.9. Җәзалар коррупцион хокук бозулар ачыкланганнан соң бер ай эчендә кулланыла. Вакытлыча эшкә яраксызлык, отпускада булу, мөһим сәбәпләр буенча эштә булмау исәпкә алынмый. Җәза бирү алты айдан да соңга калмый кулланылырга тиеш.

23.2.10. Муниципаль хезмәткәргә җәза куллану турындагы актта “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Законның 27.1 маддәсендәге 1 яки 2 частендә, әлеге Положениедә каралган җәза куллану нигез булып тора.

23.2.11. Муниципаль хезмәткәргә карата җәза куллану турындагы актның күчермәсе хокук бозуларны һәм хокукый актларны бозуын күрсәтеп яки җәза бирелмәве сәбәпләрен күрсәтеп, акт төзелгәннән соң өч көн эчендә муниципаль хезмәткәргә распискага кул куйдырып бирелә. Әгәр ул расписка бирүдән баш тарта икән, акт төзелә.

23.2.12. Муниципаль хезмәткәр федераль закон нигезендә җәзага карата

23.2.13. Әгәр муниципаль хезмәткәр җәзага тартылганнан соң бер ел дәвамында Положениенең 23 маддәсе 23.1.1 яки 23.1.2 пунктларында каралган дисциплинар җәзага тартылмаса, ул җәзасыз дип санала.

23.2.14. Эш бирүченең вәкиле җәза бирелүгә бер ел узганчы ук үз инициативасы, җитәкченең үтенеч язуы,муниципаль хезмәткәрнең язмача гаризасы нигезендә дисциплинар җәзаны алырга хокуклы.

23.2.15. Муниципаль хезмәткәргә ышанычны югалту сәбәпле эштән азат итү җәзасы турындагы белешмә җирле үзидарә органы тарафыннан ышанычны югалту сәбәпле эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә.

**6. 26 маддә 26.4 бүлек “Муниципаль хезмәткәр отпускасы” яңа редакциядә язарга:**

26.4. Муниципаль хезмәткәргә ел саен бирелә торган түләүле өстәмә сотпуск хезмәт еллары ( выслуга лет) өчен һәм федераль законда һәм әлеге Кодекста каралган очракларда бирелә. Аның дәвамлылыгы муниципаль хезмәтнең һәр елы өчен бер көн исәбеннән исәпләнә. Еллык төп түләүле отпуск һәм түләүле өстәмә отпускның дәвамлылыгы 40 календарь көннән артмаска тиеш. Нормасыз хезмәт

көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә бер хезмәт көне өчен еллык өстәмә отпуск өч көн исәбеннән бирелә.

**7. 28 маддә 28.7 бүлек "Муниципаль хезмәткәр һәм аның гаилә әгъзаларын пенсия белән тәэмин итү" яңа редакциядә язарга:**

"28.7.Хезмәт еллары өчен вазифаи оклад һәм әлеге окладка класслы чин өчен айлык өстәмә түләүдән чыгып айлык пенсия исәпләнә".

**8. " Муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын пенсия белән тәэмин итү" 28 маддәне 28.12 пункт белән түбәндәге эчтәлектә өстәргә:**

"28.12. Хезмәт еллары өен пенсия билгеләү һәм түләү турындагы мәгълүмат социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасына куела. Әлеге мәгълүматны кую (алу) "Дәүләт социаль ярдәм турында"гы Федераль закон 17 июль 1999 ел № 178-ФЗ нигезендә.